СОВЕТ ОЛУЯЗСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Шайхи Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ОЛЫЯЗАВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Шайхи Маннур ур., 72анче йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-44; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение
№ 7-7

Карар
«03» март 2016 ел

2016 елның 28 февралендә референдумда
кабул ителгән карарны теркәү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, 2015 елның 1 мартында референдум нәтиҗәләре нигезендә: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2016 елда 200 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

Тубэн Козгынчы торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау:
Татарстан урамы-300м
Олыяз торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау
С.Габдрауф урамы-600м
Югары Козгынчы торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау
Трактористлар урамы -140 м

- ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту:

Тулбай торак пунктында зират коймаларын ремонтлау: -20,0 мең сум

- торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү:
Пожарный гидрант алу хэм урнаштыру
Дусай, Кыраул торак пунктларында -45,0мен сум.

- «Әйе» «Юк»

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясенең 2016 елның 29 февралендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы «Олыяз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында» 45 номерлы карарын теркәргә.
2. Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану юнәлешләрен һәм күләмнәрен кушымта буенча билгеләргә.
3. Әлеге карарны муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /И.Я.Хаев /

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Советының 3 март, 2016 ел, № 7-7 карарына
КУШЫМТА

Гражданнарның үзара салым акчаларын куллану

юнәлешләре һәм күләмнәре

| N т/п | Җирле әһәмияттәге мәсьәләнең атамасы | Шул исәптән планлаштырылган чаралар | чараларны гамәлгә ашыруга акча күләме, мең сум |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Торак пунктлар чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге ; | Олыяз торак пунктындагы юлларны вак таш җәеп ремонтлау:<br>С.Габдрауф урамы<br>Тубэн Козгынчы торак пунктында: :<br>Югары Козгынчы торак пунктында:<br>Трактористлар урамы | 104,0 |
| 2. | ритуаль хезмәтләр оештыру һәм җирләү урыннарын карап тоту | Тулбай торак пунктларында зират коймаларын ремонтлау; | 20,0 |
| 3 | торак пунктлар чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү | Пожарный гидрант алу хэм урнаштыру Дусай, Кыраул торак пунктларында | 45,0 |
| Барлыгы | | | 169,0 |